| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МОЛЬКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>МӘЛКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.11.2022 Мәлки ав. № 45

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2015 елның 26 октябрендәге 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2015 елның 26 октябрендәге 8 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяның 3пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнеше чикләнгән җир кишәрлекләренә карата 0,3 %.».

1.2. 4 статьяда:

1.2.1. 4 абзацта «администрацияләр» сүзен «идарәче компанияләр» сүзләренә алмаштырырга;

1.2.2. түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«- «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары (алга таба - хәрби хезмәткәрләр) һәм аларның гаилә әгъзалары.

Хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзалары дигәндә түбәндәгеләр аңлашыла:

1) хәрби хезмәткәр белән никахта торучы ир яисә хатын;

2) хәрби хезмәткәрләрнең 18 яшькә җитмәгән яисә бу яшьтән өлкәнрәк балалары, әгәр алар 18 яшькә җиткәнче инвалид булган булсалар, шулай ук көндезге бүлектә белем алучылар - уку тәмамланганчыга кадәр, әмма алар 23 яшькә җиткәннән дә соңга калмыйча.».

1.3. 3 статьяда:

1.3.1. 3,4 абзацларны төшереп калдырырга;

1.3.2. 3 статьяны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырыга:

«Салым буенча салым һәм аванс түләүләре салым түләүчеләр-оешмалар тарафыннан Россия Федерациясе Салым кодексының 389 статьясы нигезендә салым салу объекты дип таныла торган җир кишәрлекләре урнашкан урын буенча бюджетка түләнә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның 1 пунктының 1.2.2 пунктчасы нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2021 елның салым чорында җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/molkeev kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында бастырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Мәлки авыл җирлеге Башлыгы Ф.П.Поляков